КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 сентябрь г.Казань № 1062

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы турында» 2014 ел, 13 август, 585 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы эшчәнлеге һәм аннан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы турында» 2014 ел, 13 август, 585 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 июль, 560 нчы, 2022 ел, 15 ноябрь, 1216 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы эшчәнлеге һәм аннан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин